СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Ул. Советская, д.62, с. Татарское Бурнашево,
422579

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Совет ур., 62 нче йорт, Татар Бурнашы авылы,
422579

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ — КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

18.12.2024 с. Татарское Бурнашево 45-243

Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында

Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү һәм камилләштерү, аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген кызыксындыру максатларында, "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 02.04.2007 елгы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында 25.06.2013 елгы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә,"Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында" Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.03.2018 ел, № 182 карарына таянып,Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Уставы белән,

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Расларга

- Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен (1 нче кушымта);
- тиешле елларны эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладына айлык өстәмә түләүне башкару тәртибе һәм күләме (2 нче кушымта)
- муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладына айлык өстәмә түләүне башкару һәм аның күләме (3 нче кушымта)
- аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләрне түләү тәртибен һәм күләмнәрен (4 нче кушымта);
- айлык акчалата бүләкләүне башкару тәртибе һәм аның күләме (5 нче кушымта);

- муниципаль хезмәткәргә класслы чин өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм аның күләме (6 нчы кушымта);

- еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүне башкару тәртибе һәм күләмнәре (7 нче кушымта);

- матди ярдәм күрсәтү тәртибе һәм күләмнәре (8 нче кушымта);

- норматив булмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык компенсация түләүләрен билгеләү һәм исәпләү турында нигезләмә (9 нчы кушымта);

- профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык өстәмә түләүне башкару тәртибе һәм күләмнәре (10 нчы кушымта);

- Татарстан Республикасы дәүләт бүләге өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләмнәре (11 нче кушымта);

- Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге башлыгының акчалата түләү күләме, (12 нче кушымта);

- Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын төзү тәртибе һәм күләмнәре (13 нче кушымта).

2. Билгеләргә:

2.1. Җирлек башлыгына, айлык акчалата бүләкләүдән һәм еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләүдән тыш, өстәмә рәвештә айлык акчалата бүләкләү, айлык бүләкләүгә тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү, эш нәтиҗәләре буенча премияләр түләнергә, шулай ук муниципаль хокукый актлар нигезендә башка түләүләр башкарылырга мөмкин.

Айлык акчалата бүләкләүгә чыгымнар күләме Бурнаш авыл җирлеге башлыгы өчен елына 12,86 айлык акчалата бүләкләүне тәшкил итүче нормативтан артып китә алмый.

Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләүгә чыгымнар күләме тиешле вазыйфа буенча елына өч айлык акчалата бүләкне тәшкил итә торган нормативтан арта алмый.

3. «Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге депутатларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Советының 21.06.2024 ел № 40-220 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни мәсьәләләр, хокук тәртибе һәм регламентлар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С.В.Бурукин

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге
Советының 18.12.2024 ел
№ 45-243 карарына
1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләме

| Вазифа атамасы | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет секретаре | 18607 |

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге
Советының 18.12.2024 ел
№ 45-243 карарына

2 кушымта

.

Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладына айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләмнәре

1. Муниципаль хезмәттә тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмәләр муниципаль хезмәт стажына түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Муниципаль хезмәт стажы | Өстәмә күләме (процентларда) |
|---|---|
| 1 елдан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 елдан 10 елга кадәр | 10 |
| 10 елдан 15 елга кадәр | 15 |
| 15 елдан артык | 20 |

2. Тиешле еллар эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләү билгеләү өчен муниципаль хезмәт стажы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органы акты белән билгеләнә.

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге
Советының 18.12.2024 ел
№ 45-243 карарына

3 кушымта

.

Муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи окладына айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләмнәре

1. Муниципаль хезмәтнең аерым шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә җирле үзидарә органының норматив акты белән, һөнәри әзерлеген, белгечлек буенча эш тәҗрибәсен һәм муниципаль хезмәтнең билгән вазыйфасын исәпкә алып, муниципаль хезмәткәргә вазыйфаи окладның 9 проценты күләмендә билгеләнә.

2. Муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен өстәмәләр түбәндәге шартларның берсе булганда түләнә:

1) җирле үзидарә органнарының хокукый актлары белән төзелгән комиссияләр, коллегияләр яисә консультатив иҗтимагый советлар эшендә катнашу;

2) идарә эшчәнлеге тәҗрибәсенә ия булу (җитәкче вазыйфаларда, муниципаль хезмәт вазыйфаларында яисә дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында эш стажы булу) кимендә өч ел;

3) норматив хокукый актлар проектларын әзерләүгә турыдан-туры бәйле эш башкару.

3. Муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен өстәмәләр тиешле җирле үзидарә органы җитәкчесенең хокукый акты белән аның күләмен билгеләгән көннән башлап түләнә.

4. Муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен өстәмәләр муниципаль хезмәткәргә акчалата түләү белән бер үк вакытта түләнә.

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге
Советының  18.12.2024 ел
№ 45-243 карарына
4 кушымта

Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләрне башкару тәртибе һәм түләү күләмнәре

1. Муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү, җирле үзидарә органнарына йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү максатларыннан, башкарыла торган бурычларның сыйфатын яхшырту, вазыйфаи инструкциядә каралган вазыйфаи бурычларны вакытында һәм намус белән үтәгән өчен тиешле җирле үзидарә органы җитәкчесенең хокукый акты нигезендә муниципаль хезмәткәрләргә аларның аеруча мөһим һәм катлаулы бурычларын үтәгән өчен максималь күләмдә премияләр бирелергә мөмкин.

2. Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә премияләр түләү, әлеге Тәртип нигезендә кабул ителгән җирле үзидарә органы (муниципаль орган) җитәкчесе карары буенча муниципаль орган бурычларын һәм функцияләрен тәэмин итүне, вазыйфаи инструкцияне үтәүне исәпкә алып башкарыла.

Аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премия бер үк вакытта муниципаль хезмәткәргә акчалата түләү белән бергә  җирле үзидарә органының хезмәт өчен түләү фонды акчалары исәбеннән аның күләмен тиешле җирле үзидарә органы җитәкчесенең хокукый акты билгеләгән көннән алып түләнә.

2.1. Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге башлыгы тәкъдиме буенча һөнәри бәйрәмнәре һәм бәйрәм көннәренә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрләргә премияләр түләнә ала (Җирле үзидарә көне, Сабантуй, Республика көне, Яңа ел һ.б.).

3. Премияләр муниципаль хезмәткәрләргә яллаучының (эш бирүче) вәкиле тарафыннан җирле үзидарә органының яисә муниципаль органның хезмәт өчен түләү фондында каралган акчалар чикләрендә шул максатларга түләнә һәм түбәндәгеләргә бәйле рәвештә билгеләнә:

- җирле үзидарәнең тиешле органына йөкләнгән бурычларны, вазыйфаларны үтәүне тәэмин итү һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча хезмәткәрнең шәхси өлеше;
- хезмәткәрләрнең биремнәрне үтәүнең катлаулылыгы, мөһимлеге һәм сыйфаты, ирешелгән нәтиҗәләрнең нәтиҗәлелеге;
- хезмәткәрнең вазыйфаи инструкцияне башкару нәтиҗәләре;
- хезмәт дисциплинасын үтәү.

4. Үз вазыйфаи бурычларын үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә премия тулысынча яисә өлешчә түләнмәскә мөмкин.

Шул ук вакытта вазыйфаи бурычларны үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү фактлары документаль рәвештә расланырга тиеш.

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге
Советының 18.12.2024 ел
№ 45-243 карарына
5 кушымта

Айлык акчалата бүләкләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм түләү күләмнәре

1. Муниципаль хезмәткәрләргә премиядән тыш ай саен акчалата бүләкләү түләнә. Муниципаль хезмәткәрләргә ай саен акчалата бүләкләү вазыйфаи окладның 41 %ыннан артмаган күләмдә җирлек башлыгының боерыгы белән билгеләнә.

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге
Советының 18.12.2024 ел
№ 45-243 карарына
6нчы кушымта

Муниципаль хезмәткәргә класс чины өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләмнәре

Муниципаль хезмәткәргә,артык булмаган күләмнәрдә, класс чины өчен айлык өстәмә түләү билгеләнә:

| Класс чины | Класс чины өчен өстәмә түләү күләме, вазыйфаи окладка карата процент |
|---|---|
| I класслы хакыйкый муниципаль киңәшче | 7 |
| II класслы хакыйкый муниципаль киңәшче | 5 |
| III класслы хакыйкый муниципаль киңәшче | 3 |

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге
Советының 18.12.2024 ел
№ 45-243 карарына

7нче кушымта

Еллык түләүле отпуск биргәндә бер тапкыр бирелә торган түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләмнәре

1. Муниципаль хезмәткәрләргә еллык түләүле отпуск биргәндә, 1,2 вазыйфаи окладтан артмаган күләмдә бер мәртәбә түләнә торган түләү башкарыла.

1.1. Еллык түләүле отпускны җирлек башлыгына биргәндә бер тапкыр түләнә торган түләү елына бер айлык акчалата түләүдән артмаган күләмдә түләнә.

2. Ел саен түләүле отпуск муниципаль хезмәткәргә өлешләр буенча бирелгән очракта, бер тапкыр түләнә торган түләү муниципаль хезмәткәр сайлау буенча отпуск өлешләренең берсенә бирелгәндә башкарыла.

3. Аерым очракларда муниципаль хезмәткәрнең гаризасы нигезендә бер тапкыр бирелә торган түләү өлешләр буенча башкарылырга мөмкин.

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге
Советының 18.12.2024 ел
№ 45-243 карарына

8нче кушымта

Матди ярдәм күрсәтү тәртибе һәм күләмнәре

1. Матди ярдәм күрсәтү муниципаль хезмәткәрнең хезмәткә түләүнең билгеләнгән фонды чикләрендә матди ярдәм күрсәтү турындагы гаризасы нигезендә башкарыла.

2. Аерым очракларда матди ярдәм өстәмә рәвештә бала туганда, тантаналы, юбилей датасына җирле үзидарә органы җитәкчесе ихтыяры буенча, шулай ук хезмәткәр һәм аның якын туганнарының каты авыруы, үлеме һәм башка бәхетсезлек очраклары булганда һ. б. түләнергә мөмкин.

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге
Советының 18.12.2024 ел
№ 45-243 карарына

9нчы кушымта

Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен муниципаль хезмәткәрләргә айлык компенсация түләүләрен билгеләү һәм исәпләү турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Нигезләмә норматив булмаган хезмәт көне шартларында муниципаль хезмәткәрләргә айлык эш өчен компенсация түләүләрен билгеләү, исәпләү һәм түләү тәртибен билгели.

2. Түләүне билгеләү тәртибе һәм шартлары

2.1. Нормалаштырылмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләве вазыйфаи окладның 2 проценты күләмендә билгеләнә.
2.2. Түләүне башлау ай саен башкарыла, һәм ул акчалар белән бергә җирле үзидарә органының хезмәткә түләү фонды акчалары исәбеннән түләнә.
2.3. Муниципаль хезмәткәрләргә түләүне билгеләү турындагы карар авыл җирлеге башлыгы тарафыннан кабул ителә.

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге
Советының 18.12.2024 ел
№ 45-243 карарына
10нчы кушымта

Профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык өстәмә түләүне гамәлгә ашыру тәртибе һәм күләмнәре

1. Өстәмә түдәүләр билгеләү өчен муниципаль хезмәткәрнең тиешле документ белән расланган профильле гыйльми дәрәҗәсе булу нигез була.

Фән дәрәҗәсенең профильлелеге буенча таләпләр җирле үзидарә органнарының функцияләре белән билгеләнә һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең хокукый актлары белән билгеләнә.

2. Берничә нигез буенча алырга хокукы булган муниципаль хезмәткәргә гыйльми дәрәҗәсе өчен түләү муниципаль хезмәткәр сайлау буенча бер нигез буенча билгеләнә. Өстәмә түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

а) фәннәр кандидатының гыйльми дәрәҗәсе өчен - вазыйфаи окладның 1 проценты;

б) фәннәр докторының гыйльми дәрәҗәсе өчен - вазыйфаи окладның 2 проценты.

3. Өстәмә түләүләр ай саен алына һәм акчалар белән бергә җирле үзидарә органының хезмәткә түләү фонды акчалары исәбеннән түләнә.

4. Өстәмә түләүләр гыйльми дәрәҗәсен бирүне раслый торган тәкъдим ителгән документ нигезендә билгеләнә. Муниципаль хезмәткәргә өстәмәләр билгеләү турындагы актның гамәлдә булуы, әлеге карарның гамәлдә булу шарты белән, билгеләнгән вазыйфасында аның бөтен эш чорына кагыла.

5. Муниципаль хезмәткәргә өстәмәләр билгеләү турындагы карар җирлек башлыгы тарафыннан кабул ителә

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге
Советының 18.12.2024 ел
№ 45-243 карарына

11нче кушымта

Татарстан Республикасы дәүләт бүләге өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәмә түләүләр башкару тәртибе һәм аларның күләмнәре

1. Өстәмә билгеләү өчен муниципаль хезмәткәрнең тиешле документ белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт бүләге булуы нигез була.

2. Татарстан Республикасы дәүләт бүләге булган муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә түләү вазыйфаи окладның 2 проценты күләмендә билгеләнә.

Берничә нигездә аны алу хокукына ия муниципаль хезмәткәргә Татарстан Республикасы Дәүләт бүләге өчен өстәмә муниципаль хезмәткәр сайлавындагы нигезләрнең берсе буенча билгеләнә.

3. Өстәмәләрне исәпләү ай саен башкарыла һәм акчалар белән бергә җирле үзидарә органының (муниципаль орган) хезмәт өчен түләү фонды акчалары исәбеннән түләнә.

4. Муниципаль хезмәткәрләргә өстәмәләр билгеләү турындагы карар җирлек башлыгы тарафыннан кабул ителә.

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге
Советының  18.12.2024 ел
№ 45-243 карарына

12нче кушымта

Бурнаш авыл җирлеге башлыгының акчалата бүләкләү күләме

| Вазифа атамасы | Акчалата түләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җирлек башлыгы | 19173 |

Югары Ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге
Советының 18.12.2024 ел
№ 45-243 карарына
13нче кушымта

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү фондын булдыру тәртибе һәм күләме

Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда вазыйфаи окладларны түләү өчен җибәрелә торган акчаларның суммасыннан тыш, түләү чаралары каралган (бер елга исәпләгәндә):

1) класс чинына айлык өстәмәләр - вазыйфаи окладларның дүрт процентыннан артмаган күләмдә;

2) муниципаль хезмәттә тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмәләр - вазыйфаи окладларның унөч процентыннан артмаган күләмдә;

3) муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен айлык өстәмәләр - вазыйфаи окладларның биш процентыннан артмаган күләмдә;

4) аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премияләр - вазыйфаи окладларның бер процентыннан артмаган күләмдә;

5) еллык түләүле отпуск биргәндә бер мәртәбә түләнә торган түләү - вазыйфаи окладларның ун процентыннан артмаган күләмдә;

6) айлык акчалата бүләкләү - вазыйфаи окладларның 41 процентыннан артмаган күләмдә.

7) норматив каралмаган хезмәт көне шартларында эшләгән өчен айлык компенсация түләүләре, юридик эш өчен өстәмәләр һәм профильле гыйльми дәрәҗә өчен айлык хезмәт хакын өстәмә түләү - вазыйфаи окладларның 2,5 процентыннан артмаган күләмдә.